# КАРАР (РЕШЕНИЕ)

## "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе" муниципаль берәмлегенең Байлар Сабасы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

19.09.2022 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясы нигезендә, 12нче, 13нче, 14нче, 15нче, 16нчы сентябрь көннәрендә «Сез 2023 нче елда "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы бистәсе" муниципаль берәмлегенә керүче Байлар Сабасы торак пунктында, яшәү урыны буенча "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе" муниципаль берәмлегенең Байлар Сабасы торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?" мәсьәләсе һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәнең тротуарларын һәм су агу улакларын төзекләндерү һәм төзү (нигез салу, бетон һәм асфальт салу, килешү һәм муниципаль контракт буенча эшләр өчен түләү);
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсендә тышкы яктырту челтәрләрен урнаштыру, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау (җир асты корылышы, тышкы яктырту челтәрләре буенча эшләр башкару, терәкләр урнаштыру, килешү һәм муниципаль контракт буенча түләү);
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсендәге паркларны һәм балалар мәйданчыкларын карап тоту, җиһазлау (җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонт, төзекләндерү эшләре, килешү һәм муниципаль контракт буенча түләү);
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсендә агачлар һәм куаклар утырту (үсентеләр сатып алу, килешү һәм муниципаль контракт буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсендә су һәм газ белән тәэмин итү челтәрләрен проектлаштыру, төзү, ремонтлау (проект документларын төзү, су һәм газ белән тәэмин итү системаларын төзү (ремонтлау), килешү һәм муниципаль контракт буенча түләү)" соравын үз эченә алган узган җыеннар нәтиҗәләре нигезендә гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 6486 катнашучы кертелгән, шуның 3287се тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ" позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 3135 кеше тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 152 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлегенең Байлар Сабасы бистәсе торак пунктында халык җыенын үткән дип, аның нәтиҗәләрен чын дип танырга.

2. «Сез 2023 нче елда “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы бистәсе” муниципаль берәмлегенә керүче Байлар Сабасы торак яшәү урыны буенча “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлегенең Байлар Сабасы торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?" дигән мәсьәлә буенча карар кабул итәргә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәнең тротуарларын һәм су агу улакларын төзекләндерү һәм төзү (нигез салу, бетон һәм асфальт салу, килешү һәм муниципаль контракт буенча эшләр өчен түләү);
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсендә тышкы яктырту челтәрләрен урнаштыру, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау (җир асты корылышы, тышкы яктырту челтәрләре буенча эшләр башкару, терәкләр урнаштыру, килешү һәм муниципаль контракт буенча түләү);
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсендәге паркларны һәм балалар мәйданчыкларын карап тоту, җиһазлау (җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонт, төзекләндерү эшләре, килешү һәм муниципаль контракт буенча түләү);
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсендә агачлар һәм куаклар утырту (үсентеләр сатып алу, килешү һәм муниципаль контракт буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсендә су һәм газ белән тәэмин итү челтәрләрен проектлаштыру, төзү, ремонтлау (проект документларын төзү, су һәм газ белән тәэмин итү системаларын төзү (ремонтлау), килешү һәм муниципаль контракт буенча түләү)” карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/saba адресы буенча һәм җирлектә урнашкан мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Саба шәһәр
җирлеге башлыгы урынбасары

Л.Р.Фәйзетдинов